**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4402**
**01.07.2021**

Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон формада, дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр һәм социаль әһәмияткә ия дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә күчү буенча чаралар планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында игезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3645 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) муниципаль хезмәтлр исемлегендә:

- 40, 75, 76 пунктларны төшереп калдырырга;

- 34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. Россия Федерациясе Архив фонды һәм башка архив документлары нигезендә физик һәм юридик затларны мәгълүмат белән тәэмин итү, архив белешмәләрен, архив өземтәләрен һәм архив документларының күчермәләрен бирү»;

- 56 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«56. Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү»;

- 61 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«61. Җир участоклары бирмичә һәм сервитут, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участогыннан файдалануга рөхсәт бирү»;

- 67 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«67. Муниципаль милектәге җир участогына карата сервитут (җәмәгать сервитуты) билгеләү»;

- 68 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«68. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү»;

- түбәндәге эчтәлектә 80 - 89 пунктлар өстәргә:

«80. Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкарылуны тикшерү акты бирү»;

«81. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренешен килештерү турында карар бирү.»;

«82. Капиталь төзелеш объектын сүтүне планлаштыру турында белдерү кәгазе һәм капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында белдерү кәгазе җибәрү.»;

«83. Җирләрне яки җир участокларын билгеле бер категориягә кертү яки җирләрне яки җир участокларын бер категориядән икенче категориягә күчерү»;

«84. Даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм даими йөртүләр маршруты карталарын рәсмиләштерү, даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклыкларны һәм даими йөртүләр маршруты карталарын яңадан рәсмиләштерү»;

«85. Территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү һәм раслау»;

«86. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемсез милекне бирү»;

«87. Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану»;

«88. Спорт судьясы квалификация категориясе бирү»;

«89. Спорт разряды бирү»;

2) дәүләт хезмәтләре исемлегендә 24 пунктны төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов